# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

№ 6 30 март 2016 ел

Хөкем ителгәннәрнең җәзасын үтәү өчен объектлар һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында

РФ Җинаять кодексы нигезендә 49 статьясының 1 өлеше, 25 статьясының 1 өлеше нигезендә. РФ Җинаять башкарма кодексының Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгәннәр җәзасын үтәгәндә, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә җинаять җәзасы билгеләнгән затларны төзәтү, аларда җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә хөрмәтле мөнәсәбәт формалаштыру максатларында Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ::

1. Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә: Яңа Аксубай авылы, Кисы авылы, Азат авылы, Федоровка Бистәсе, кече Аксубай авылы җинаять – башкару инспекциясе белән килешү буенча.
2. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә - торак пунктларны төзекләндерү һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, юллар һәм буалар буендагы куакларны кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, җинаять-башкару инспекциясе белән килешү буенча юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау.
3. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы белән берлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларга карата суд карарларының үтәлешен тәэмин итү өчен җибәрергә.
4. ТР Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитетының 24.02.2016 елның 5 № - лы карары үз көчен югалткан дип танылсын.
5. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе М.М.Сулейманкин